КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 май г.Казань № 390

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда картлык һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсиясен алучы булган эшләми торган пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау һәм 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 1 октябрь, 708 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 8 октябрь, 751 нче карарының 2 нче, 3 нче пунктлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарын компенсацияләү турында» 2019 ел, 14 май, 390 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына компенсация бирү турында» 2019 ел, 13 июль, 574 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарын компенсацияләү турында» 2019 ел, 14 май, 390 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 28 август, 707 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсация бирү чыгымнарын финанслау тәртибен раслау турында» 2019 ел, 2 сентябрь, 752 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин